# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

## 2026 елда Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Куралово авылы җирлегенең Куралово авылы торак пунктында гражданнарның үзара салымын кертү турында

2025 елның 15 ноябре №1

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33 - ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Куралово авыл җирлегенең Куралово авылында гражданнар җыены

КАРАР ИТТЕ:

1. Югары Ослан муниципаль районының Куралово авылы җирлегенең Куралово авылында яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 100% -СВОда катнашучылар, контрактчылар һәм аларның гаилә әгъзалары, 1 төркем инвалидлар; хезмәтчәннәреннән тыш, 2026 елда үзара салымны 700 сум күләмендә кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

Куралово торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (билгеләнгән урынга илтеп җиткереп, асфальт гранулят сатып алу).

Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, Куралово авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Югары Ослан муниципаль районы
Куралово авыл җирлеге башлыгы Р.Е.Тарасов